**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 23 декабрендәге 4646 номерлы карары**

# Казан шәһәрендә «Әкият» курчак театры янындагы парк территориясендә чаралар уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

«Әкият» курчак театры янындагы парк территориясендә чаралар уздыруны оештыру максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2025 елның 23 декабреннән 2026 елның 1 мартына кадәр «Әкият» курчак театры янындагы парк территориясенә якын урнашкан юлларда, Петербург урамыннан Тихомирнов урамына кадәр, «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан билгеләнгән форма буенча махсус рөхсәтнамә белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны чикләүне кертергә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.2. хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында юл билгеләрен урнаштыруда һәм каплауда ярдәм күрсәтергә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техника урнаштыруда ярдәм күрсәтергә;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**